2023 елда Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Ямаш авылы җирлеге Нолинка авылында гражданнарның үзара салымын кертү турында

ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

13 ноябрь 2022 ел № 8

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Ямаш авыл җирлегенең Нолинка авылында гражданнар җыены карар кабул итте:

1. 2023 елда Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Ямаш авыл җирлегенең Нолинка авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәм даими яшәүче һәр балигъ булган кешедән 1000 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә: юлларны норматив хәлгә китерү, территорияләрне тезекләндерү, сметалар төзү, техник күзәтчелек үткәрү һәм җирлек милкенә рәсмиләштерү өчен түләү.

3. Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, Нолинка авылы, Лесная урамы, 3 йорт территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә, «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм кабул ителгәннән соң 10 кен эчендә Әлмәт муниципаль районы сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Ямаш авыл җирлеге башлыгы Е.С.Ларин